РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ МИЧАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422055, Республика Татарстан,
Сабинский район,
Село Старый Мичан , ул. Школьная, 12
тел. (84362) 42-3-31

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МИЧӘН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422055, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Иске Мичэн авылы, Мэктэп урамы, 12 йорт
тел. (84362) 42-3-31

e-mail: Mich.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
20.08.2026

КАРАР
№20

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советының 30.04.2018 №9 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазифаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

07.06.2025 ел №144-ФЗ, Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 135 ст. Федераль закон нигезендә һәм ТР Саба муниципаль районы прокурорының 14.08.2026 ел №02-08-02-2026/прдп 360-26 протесты нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советының 30.04.2018 ел, №9 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазифаи затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (Советның 09.11.2020 №12, 17.10.2022 №16, 19.12.2022 №22, 20.08.2024 №16, 13.11.2024 №27, 25.04.2025 №11, 17.12.2025 №16 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.5 нче бүлекнең 5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4.Хезмәткәргә дисциплинар җаваплылыкка тартылган өчен дисциплинар түләтү кулланылуга бәйле рәвештә, хезмәт хакының премия өлешен киметү хезмәткәргә карата тиешле дисциплинар түләтү кулланылган чор өчен, хезмәткәрнең хезмәт хакы составына керә торган премияләргә карата гына гамәлгә ашырыла, ә премияне мондый киметү күләме хезмәткәрнең айлык хезмәт хакы күләмен 20 проценттан артыграк киметүгә китерә алмый”.

2.Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районының Мичән авыл

җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/michan адресы буенча бастырып чыгарырга.

Мичән авыл
җирлеге башлыгы А.Ә.Гәрәев